**ХАЛЫК ҖЫЕНЫ**
**КАРАРЫ**

**№ 1** **29 ноябрь 2019 ел**

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль
районы Әсәй авыл җирлеге составына керүче
Әсәй авылында гражданнар җыены
нәтиҗәләре турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, 2019 елның 29 ноябрендә түбәндәге сорау буенча узган, гражданнар җыены нәтиҗәләре белән беркетмә төзелде:

« Сез, 2020 елда Әсәй авыл җирлеге Әсәй торак пункты территориясендә 1 Төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан һәм катнашучылардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, көндезге уку формасында укучы студентлардан тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 400 (Дүрт йөз) сум күләмендә үзара салым кертү һәм бу акчаларның җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- Әсәй авылында урамнарны яктырту, яктырткычлар, махсус җиһазлар сатып алу, энергия саклаучы лампалар урнаштыру, килешү буенча эш өчен түләү;
- Әсәй авылы Үзәк, Тау асты, Елга арты, Ясле, Мәктәп һәм Наратлы урамнары буенча вак таш (щебенка) җәю (сатып алу, ташу, вак таш җәю, килешү буенча эшләр өчен түләү);
- Әсәй авылында юлларны кардан чистарту;
- Әсәй авылында җәйге чорда территорияне чабу;
- Әсәй авылында (зиарат, мәчет, мәдәният йорты, ФАП, балалар бакчасы территорияләрендә) коры агач, куаклар кисү, чабу;
- Әсәй авылында су белән тәэмин итү челтәрләрен ремонтлау (материал, җиһазлар сатып алу, өзеклекләрне бетерү, торбаларны алыштыру, килешү буенча эш өчен түләү);
- Әсәй авылында бәйрәм чараларын («Яңа ел», «Җиңү көне», «Сабантуй», «Халыкара өлкәннәр көне») оештыру һәм үткәрү;
- Әсәй авылында янгын сүндерү депосын тоту (электр энергиясе һәм җылылык өчен түләү).

ӘЙЕ ЮК».

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Җыенда, сайлау хокукына ия булучы катнашучылар исемлегендә 379 кеше теркәлгән, җыенда тавыш бирүдә катнашучылар саны - 265 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

халык җыенында катнашучы 265 кеше «Әйе» позициясе өчен тавыш бирде;

«Юк» позициясе өчен җыенда катнашучы 0 тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар чыгарды:

1. Азнакай муниципаль районы Әсәй авыл җирлеге составына керүче Әсәй авылында узган халык җыенын узган, халык җыены нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.

2. Түбәндәге сорау буенча карарны кабул итәргә: « Сез, 2020 елда Әсәй авыл җирлеге Әсәй торак пункты территориясендә 1 Төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан һәм катнашучылардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, көндезге уку формасында укучы студентлардан тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 400 сум күләмендә үзара салым кертү һәм бу акчаларның җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- Әсәй авылында урамнарны яктырту, яктырткычлар, махсус җиһазлар сатып алу, энергия саклаучы лампалар урнаштыру, килешү буенча эш өчен түләү;
- Әсәй авылы Үзәк, Тау асты, Елга арты, Ясле, Мәктәп һәм Наратлы урамнары буенча вак таш (щебенка) җәю (сатып алу, ташу, вак таш җәю, килешү буенча эшләр өчен түләү);
- Әсәй авылында юлларны кардан чистарту;
- Әсәй авылында җәйге чорда территорияне чабу;
- Әсәй авылында (зиарат, мәчет, мәдәният йорты, ФАП, балалар бакчасы территорияләрендә) коры агач, куаклар кисү, чабу;
- Әсәй авылында су белән тәэмин итү челтәрләрен ремонтлау (материал, җиһазлар сатып алу, өзеклекләрне бетерү, торбаларны алыштыру, килешү буенча эш өчен түләү);
- Әсәй авылында бәйрәм чараларын («Яңа ел», «Җиңү көне», «Сабантуй», «Халыкара өлкәннәр көне») оештыру һәм үткәрү;
- Әсәй авылында янгын сүндерү депосын тоту (электр энергиясе һәм җылылык өчен түләү).

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru, Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча: http://aznakaevo.tatarstan.ru. һәм түбәндәге адреслар буенча урнашкан мәгълүмат стендларында урнаштырырга:

ТР, Азнакай муниципаль районы, Әсәй авылы, Үзәк ур.,38Б йорт;

ТР, Азнакай муниципаль районы, Әсәй авылы Елга Аръягы ур., 27 йорт;

ТР, Азнакай муниципаль районы, Әсәй авылы, Үзәк ур., 60 йорт;

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Әсәй авыл җирлеге башлыгына Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Әсәй авыл җирлеге Башлыгы — Идрисов З.Ә.